| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«КЕРЛИГАЧСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«КИРЛЕГӘЧ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ<br>2026 елның 2 марты | КАРАР<br>№4 |

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында карарының кереш өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ»;

2. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2022 елның 18 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Кирлегәч авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 2 статьяның 2 өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләрен «гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон белән» сүзләренә алмаштырырга»;

б) 3 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Депутатның вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

1) үлем;

2) үз теләге белән отставкага китү;

3) суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез яисә хокуктан файдалану сәләте чикләнгән дип танылу;

4) суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылса яисә вафат дип игълан ителсә;

5) аңа карата судның гаепләү карары закон көченә керүе;

6) Россия Федерациясеннән читкә даими яшәү урынына чыгу;

7) Россия Федерациясе гражданлыгын туктату яисә чит ил дәүләтенең гражданлыгы (подданствосы) йә яшәүгә рөхсәт кәгазе яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ булу;

8) тиешле җирле үзидарә органының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату;

9) хәрби хезмәткә чакыру яисә аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә юллама;

10) чит ил агенты статусын алу;

11) әлеге Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән башка очраклар.»;

в) 6 статьяның 2 өлешендә «мөмкин» сүзен «хокуклы» сүзләре белән алыштырырга;

г) 7 статьяның 3 өлешендә «хокуклы» сүзен «хокукына ия» сүзләренә алыштырырга;

д) 8 статьяның 2 өлешендә «мөмкин» сүзен «хокуклы» сүзләре белән алыштырырга;

е) 10 статьяның 3 өлешендә «имзаланырга тиеш» сүзләрен «имзалана» сүзе белән алыштырырга;

ж) 11 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«4. Депутат мөрәҗәгатенә җавап барлык сорауларга җавапларны үз эченә алырга һәм адресланган вазифаи зат яки аның вәкаләтле заты имзасы белән расланырга тиеш.»;

з) 17 статьяның 1 өлешенең 10 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«10) үз чыгымнары, шулай ук хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балалары чыгымнары турында мәгълүмат бирергә тиеш, дәүләт вазифаларын биләүче затларның һәм башка затларның керемнәренә туры килүче чыгымнарны контрольдә тоту турында 03.12.2012 № 230-ФЗ Федераль законы нигезендә чыгымнар турында мәгълүмат бирү өчен нигезләр барлыкка килгән очракта – мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соңгы елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча.»;

и) 18 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бирергә:

«1. Даими нигездә үз вәкаләтләрен башкаручы депутат хокуклы түгел:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерция яисә коммерциягә карамаган оешма белән идарә итүдә катнашу, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш,

гараж кооперативларының, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу;

б) Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Башлыгына (Раисына) алдан хәбәр итеп, коммерциягә нигезләнмәгән оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашу (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә катнашудан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләре ширкәтләренең съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашудан тыш);

в) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы Ассоциациясендә, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү;

г) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлекне исәпкә алмаганда, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнү. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе яисә Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, чит ил дәүләтләре, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары хисабына гына финанслана алмый.

4) әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүе яки Россия Федерациясе законнары белән башкасы каралмаган булса, коммерциягә нигезләнмәгән, дәүләтнеке булмаган чит ил оешмаларының идарә органнары, попечительлек һәм күзәтчелек советлары, башка органнары һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эш итүче структур бүлекчәләре составына керергә».

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Кирлегәч авылы, Совет урамы, 33А йорты, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Кирлегәч авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе С.Р.Сәлахова